| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОРЫНДЫК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 май 2025ел Борындык ав. № 97

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 14 октябрендәге 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022елның 01 апрелендәге 90 номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 14 октябрендәге 26 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтада:
- 6 пунктның «в» пунктчасында «, акцияләрне» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 16 пунктның 2 абзацында «яисә алар тарафыннан тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «үз чыгымнары турында белешмәләр, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр бирү, яисә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә, «йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында тулы

булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру яисә белешмәләр тапшырмау» сүзләрен «яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлеге Башлыгы А.Р.Гайнетдинов